РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_________________ №_________

Муниципаль милектә булган җирләрдә
стационар булмаган сәүдә объектларын
урнаштыруга шартнамә төзү буенча аукцион
уздырмыйча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" 2010 елның 2 ноябрьендәге 880 нче карарына нигезенләнеп, Башкарма комитетның “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында" 2012 елның 30 гыйнварындагы 78-п номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль милектә булган җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча аукцион уздырмыйча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга (Кушымта № 1);

2. Әлеге карарны мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресындагы Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://saby.tatarstan.ru адресындагы Саба муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары - икътисад бүлеге башлыгы М. М. Баһмановка йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Ишниязов